КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 31 март г.Казань № 323

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе мәсьәләләре» 2005 ел, 5 август, 391 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе мәсьәләләре» 2005 ел, 5 август, 391 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 5 сентябрь, 431 нче; 2005 ел, 29 декабрь, 649 нчы; 2006 ел, 1 март, 90 нчы; 2006 ел, 14 август, 415 нче; 2008 ел, 5 март, 137 нче; 2008 ел, 5 май, 289 нчы; 2009 ел, 10 июнь, 383 нче; 2010 ел, 19 июль, 574 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 7 ноябрь, 921 нче; 2011 ел, 25 ноябрь, 965 нче; 2012 ел, 31 август, 742 нче; 2013 ел, 19 гыйнвар, 21 нче; 2013 ел, 31 октябрь, 824 нче; 2014 ел, 26 февраль, 123 нче; 2015 ел, 2 октябрь, 730 нчы; 2016 ел, 26 август, 593 нче; 2018 ел, 8 август, 644 нче; 2018 ел, 31 октябрь,

976 нчы; 2018 ел, 18 декабрь, 1159 нчы; 2018 ел, 29 декабрь, 1299 нчы; 2020 ел, 17 февраль, 120 нче; 2020 ел, 24 август, 724 нче; 2020 ел, 3 ноябрь, 987 нче; 2021 ел, 17 март, 139 нчы; 2021 ел, 13 август, 720 нче; 2021 ел, 21 декабрь, 1260 нчы; 2022 ел, 26 октябрь, 1142 нче; 2023 ел, 14 гыйнвар, 9 нчы; 2023 ел, 20 март, 288 нче; 2023 ел, 14 август, 977 нче; 2023 ел, 9 октябрь, 1277 нче; 2024 ел, 27 июль, 471 нче; 2024 ел, 21 ноябрь, 1033 нче; 2025 ел, 2 июнь, 393 нче; 2025 ел, 11 июнь, 422 нче; 2025 ел, 25 август, 632 нче; 2025 ел, 24 декабрь, 1135 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе турындагы нигезләмәгә, 4.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«аеручa алдынгы хезмәткәрләрне мактаулы исемнәр бирүгә һәм дәүләт бүләкләре белән бүләкләүгә билгеләнгән тәртиптә тәкъдим итәргә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән килештереп, ведомство бүләкләрен гамәлгә куярга, бу бүләкләр турында нигезләмәләрне һәм аларның тасвирламасын расларга, ведомство бүләкләре белән Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе һәм «Кулланучылар базарын бәйсез экспертизалау һәм мониторинглау республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе хезмәткәрләрен, шулай ук башка затларны бүләкләргә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин